МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.04.2018 Казан шәһәре № под-735/18

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре» гранты турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.04.2018елның №238 «2018 елга мәгариф өлкәсендә грантлар» турындагы карарының икенче абзацы 1 нче пунктын үтәү йөзеннән, шәхесне үстерүдә тәрбиянең, өстәмә белем бирүнеж ролен арттыру максатларында б о е р а м:

1. «Тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» грантын гамәлгә куярга.

2. «Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре» гранты турында Нигезләмәне расларга.

3. Балаларга өстәмә белем бирү бүлегенә (Ж. В. Соркина) «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе (Р. А. Идрисов), дәүләт автоном белем бирү учреждениесе «Росток» психологик-педагогик ярдәм күрсәтү республика үзәге (Т.Н. Н.Бәширова) белән берлект ә «Тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» гранты чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф бүлекләре Нигезләмә нигезендә оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Балаларга өстәмә белем бирү бүлегенә (Ж. В. Соркина) боерык кабул ителгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта, аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

6. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г.К. Мухамедкаримова) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү чараларын гамәлгә ашыруга каралган акчалар кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган тәртиптә финанс ярдәмен тәэмин итәргә

6. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Л. О. Сулимага йөкләргә

Татарстан Республикасы Премьер –министр
урынбасары-министр Р.Т.Бурганов

Расланган Татарстан
Республикасы Мәгариф һәм фән
министрлыгының 23апрель 2018
ел№ под- 735/18 боерыгы белән

**«Иң яхшы тәрбия һәм балаларга өстәмә белем бирү хезмәткәре» гранты турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» грантын

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела.

Грантның максаты- белем алучы шәхеснең үсешенә, аның рухи-әхлакый үсешенә,

тормышта үз урынын табарга әзерләүдә, укучыларны социальләштерү буенча башка субъектларда эшләүче педагоглар, ата-аналарның үзара хезмәттәшлекләрен үстерүдә тәрбия, өстәмә тәрбия ролен күтәрү.

Грантның бурычлары булып тора:

тәрбия һәм балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендә белем бирү, методик һәм

җитәкчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларының, өстәмә гомуми белем бирү оешмаларының, һөнәри белем бирү оешмаларының, дәүләт бюджет оешмаларының, муниципаль мәгариф идарәсе органнарының иң яхшы хезмәткәрләрен ачыклау һәм кызыксындыру;

балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү системасында педагогик һәм җитәкче хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм хезмәт дәрәҗәсен күтәрү;

Татарстан Республикасында балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү

системасында нәтиҗәле тәҗрибәне ачыклау һәм тарату,

1.3. Грантта катнашучылар:

Грант бирүче — Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба- - Министрлык), грантлар бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Грант алучы- әлеге Нигезләмәнеңнең 1.4 пунктында билгеләнгән таләпләргә һәм Нигезләмәнең 2 бүлегендә билгеләнгән критерийларга туры килә торган, Грант алуга конкурс сайлап алуы узган физик зат,

Грант алучылар Республика комиссиясе тарафыннан билгеләнә һәм Министрлык боерыгы раслана

Гариза бирүче - грант алуырга теләүчеләрне тәкъдим итүче мәгариф оешмалары үзидарә органнары (мәгариф оешмалары советы, попечительләр советы, гомуми җыелыш, педагогик совет, мәгариф оешмасы Уставында каралган башка үзидарә органары);билгеләнгән тәртиптә булдырылган Һөнәри педагогик ассоциацияләр яки оешмалар (профильле методик берләшмәләр, белем бирү технологияләре буенча ассоциацияләр, һөнәри берлекләр),дәүләт бюджет оешмалары (балалар йортлары,

ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны яңа гаиләләргә урнаштырырга әзерләү һәм озата баруда ярдәм үзәкләре). муниципаль мәгариф идарә органнары.

1.4. Грантка дәгъва кылучылар буларак түбәндәге таләпләргне канәгатьләндерүче

педагоглар һәм җитәкчелек хезмәткәрләре дәгъва итә ала:

педагогик эшчәнлек стажы кимендә өч ел ;

эш урыны- законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмасы,өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы, дәүләт бюджет оешмасы (балалар йорты, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны яңа гаиләгә урнаштырыга әзерләү һәм озата баруда ярдәм үзәге), мәгариф идарәсенең муниципаль органы.

1.5. Грант түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының иң яхшы директоры»;

«Иң яхшы өстәмә белем бирү педагогы»;

«Иң яхшы өстәмә белем бирү методисты»;

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» (балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсе кадрларының «Кеше тәрбияләү»

һәм «Йөрәгемнебалаларга бирәм», «Педагог-психолог 2018» һөнәри осталыгы Республика конкурслары кысаларында);

«Иң яхшы педагог-оештыручы»;

«Психологик-педагогик хезмәтнең иң яхшы педагог-психологы (ПИМС-

Үзәк)»;

«Дәүләт бюджет белем бирү оешмасының иң яхшы педагог-психологы”

«Һөнәри белем биру оешмаларының тәрбия эшләре буенча иң яхшы директор урынбасары”

1.6. Грант 25 000. 30 000, 50 000 сум күләмендәге премия рәвешендә бер тапкыр бирелә торган түләү,

Грант шәхси һәм физик затларга тапшырыла алмый. Грант алучы «Һөнәри белем бирү оешмаларының тәрбия эше буенча иң яхшы директор урынбасары», «Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре», «Созвездие-йолдызлык» ачык Республика телевизион яшьләр эстрада сәнгать фестивале» номинацияләре җиңүчеләрен әзерләүче педагоглардан кала, грантта өч елга 1 тапкыр катнашырга хокуклы.

1.6.1. Грантлар саны елына 324 гранттан артмый.

1.6.2. Грантлар саны түбәндәгечә бүленә:

«Өстәмә белем бирү оешмасының иң яхшы директоры» номинацисенә 50 000 сум күләмендә 14 грант бирелә.

«Иң яхшы өстәмә белем бирү педагогы» номинациясенә 170 грант бирелә,

бу сан түбәндәгечә бүленә:

50000 сумнан 30 грант 2018 елда «Созвездие—Иолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале җиңүчеләрен әзерләгән педагогларга бирелә;

50000 сумнан 140 грант өстәмә белем бирүче педагогларга

балаларга өстәмә белем бирүенең һәр юнәлеше буенча:

сәнгать;

туристик-туган якны өйрәнү;

физкультура-спорт;

техник;

табигый;

социаль-педагогик белем алучылар санына пропорциональ бирелә.

Өстәмә белем бирүнең иң яхшы методисты» номинациясенә 50 000 сум күләмендә

1.5 Грант бирелә:

«Тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр “номинациясенә

(балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсе кадрларының «Кеше тәрбияләү» һәм «Йөрәгемнебалаларга бирәм», «Педагог-психолог 2018» Республика һөнәри осталык конкурслары кысаларында) 50 000 сум күләмендә 12 грант (1,2,3 урыннар) ,25 000 сум күләмендә 28 грант (лауреатлар) бирелә.

«Иң яхшы педагог-оештыручы» номинациясенә 50 000 сум күләмендә 30 грант бирелә

«Психологик-педагогик хезмәтнең иң яхшы педагог-психологы» (ППМС-үзәк)» номинациясенә 50 000 сум күләмендә 15 грант бирелә.

«Дәүләт бюджет оешмасы мәгариф оешмасының иң яхшы педагог-психологы» номинациясенә 30 000 сум күләмендә 25 грант бирелә.

Һөнәри белем бирү оешмаларының 2017-2018 уку елы рейтингы нәтиҗәләре буенча,

«Һөнәри белем бирү оешмасының тәрбия эшләре буенча иң яхшы директор урынбасары " номинациясенә 50 000 сум күләмендә 15 грант бирелә.

Грант акчасын түләү Грант алырга теләүчеләрне конкурс сайлап алу нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

## 2. Грант алуга конкурс сайлап алу критерийлары

2.1. «Өстәмә Белем бирү оешмасының иң яхшы директоры» номинациясендә

өстәмә белем бирү оешмаларының иң яхшы директорларын грант алуга конкурс нигезендә сайлап алу түбәндәге критерийларда уздырыла:

агымдагы елда балаларга өстәмә белем бирү мәгариф берләшмәләрендә (алга таба-БӨББМБ) белем алучы контингентның сакланышы;;

агымдагы уку елында өстәмә белем бирү оешмасының һәм педагогик хезмәткәрләрнең грант активлыгы;

сәламәтлеге чикләнгән, инвалид балаларга өстәмә белем бирү программалары буенча белем бирү процессын тәэмин итү өчен, БӨББМБнең җиһазланыш дәрәҗәсе

агымдагы уку елында бюджеттан тыш акчаларны җәлеп итү;

БӨББМБ заманча белем бирү модельләрен тормышка ашыру;

Җитәкченең өстәмә белем бирү оешмалары Директорлар советы эшчәнлегендә катнашуы;

җитәкче вазыйфасы буенча җитәкченең һөнәри конкурсларда катнашуы;

җитәкчелек итә торган балаларга өстәмә белем бирү оешмасының мәгариф оешмалары конкурсларында катнашуы;

җитәкченең эксперт эшчәнлеге (жюри әгъзасы, эксперт комиссиясе әгъзасы һәм тдп.);

өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының оештыру-методик активлыгы;

өстәмә белем бирү мәгариф оешмасы тарафыннан республика, Бөтенроссия, халыкара чаралар оештыру һәм үткәрү,

2.2.. "Балаларга өстәмә белем бирүдә иң яхшы педагогы» номинациясендә,

грант алу өчен, иң яхшы өстәмә белем бирү педагогларын сайлап алу конкурсы түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

әлеге педагогик хезмәткәр берләшмәсендә укучылар контингентының сакланышы;

соңгы өч елда укучыларның конкурс чараларында, фестивальләрдә төрле дәрәҗәдәге фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашуын тәэмин итү;

соңгы өч елда укучыларның төрле дәрәҗәдәге конкурс чараларында катнашу нәтиҗәлелеге;

педагогик хезмәткәрнең инновацион эшчәнлектә катнашуы, эксперименталь эш алып баруы, методик кулланмалар эшләү һәм яңа өстәмә гомуми белем бирү программаларын кертүе;

соңгы өч елда педагогик хезмәткәрләрнең төрле дәрәҗәдәгеге һөнәри осталык конкурсларда катнашу нәтиҗәлелеге;

берләшмәне үстерүгә грантлар җәлеп итү;

соңгы өч елда педагогик хезмәткәрнең үз педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү буенча чараларда (фәнни-гамәли,конференцияләрдә, укыту семинарларында, мастер-классларда) катнашуы (чыгышлары һәм публикацияләре);

2.2.1. 2018 елда «Созвездие-Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләрне әзерләгән өстәмә белем бирү педагогларын конкурс нигезендә сайлап алу түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

2018 елда «Созвездие-Йолдызлык»фестиваленең жюри әгъзаларының Йомгаклау протоколы нәтиҗәсенедә «Созвездие-Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә "Вокал-соло"( 1 нче кечкенәләр төркеме). "Вокал-соло (2 нче кечкенәләр төркеме),» Вокал-соло (уртанчылар төркеме (кызлар)«, "Вокал-соло" (урта төркем (малайлар)», «Вокал-соло (өлкән төркем)», " Вокаль ансамбльләр (кече төркем)»,» Вокаль ансамбльләр (уртанчылар төркеме)«, " Вокаль ансамбльләр (өлкән төркем)», «Хореография (кече төркем)», «Хореография (урта төркем), "Хореография (өлкән төркем)»," Конферанс (кечкенәләр төркеме)»,Конферанс (уртанчылар төркем)»,» Конферанс (өлкән төркем)" номинацияләрендә буенча бирелгән Грант алучының " тәрбияләнүчесе (ләре) яулаган беренче призлы урын;

2.3. «Өстәмә белем бирүнең иң яхшы методисты» номинациясендә

өстәмә белем бирү мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы иң яхшы методистларны грант алуга конкурс сайлап алу түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

соңгы өч елда өстәмә белем бирү оешмасында белем бирү процессын программалы-методик тәэмин итү сыйфаты;

өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының иң яхшы өстәмә белем бирү учреждениесе бәйгеләрендә катнашуын методик тәэмин итү;

соңгы өч елда грант алырга теләүченең төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык конкурсларында катнашу нәтиҗәлелеге;

методистның инновацион, тәҗрибә-эксперименталь эшчәнлектә катнашуы;

соңгы өч елда грант алырга теләүченең үз педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү чараларда (фәнни-гамәли конференцияләрдә, укыту семинарларында, мастер-классларда) катнашуы (оештыру, чыгышлар һәм публикацияләр);

соңгы өч елда фәнни-методик эшчәнлектә катнашуы, фәнни басмаларда мәкаләләр

бастыруы;

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының стажер мәйданчыклары, семинарлар, мастер-класслар һәм грант алырга теләүченең эшчәнлек юнәлеше буенча

башка муниципаль, региональ яисә федераль масштабтагы чаралар үткәрүе.

2.4. “Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре “ номинациясендә(балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендәге кадрларның һөнәри осталык Республика конкурсы кысаларында)) грант алу га конкурс сайлап алу түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

Балаларга өстәмә белем бирү педагогларының Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре Республика конкурсы кысаларында «Йөрәгемне балаларга бирәм» Һөнәри осталык Республика конкурсында 1, 2 һәм 3 урын;

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре» Республика конкурсы кысаларында «Сыйныф җитәкчесе» номинациясендә «Кеше тәрбияү» Һөнәри осталык республика конкурсында 1, 2 һәм 3 урын;

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре» Республика конкурсы кысаларында " Педагог-оештыручы»; номинациясендә «Кеше тәрбияү» Һөнәри осталык республика конкурсында 1, 2 һәм 3 урын;

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре» Республика конкурсы кысаларында «Иң яхшы педагог-психолог» номинациясендә «Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшыхезмәткәр» Һөнәри осталык республика конкурсында 1, 2 һәм 3 урын;

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» Республика крнкурсы кысаларында «Йөрәгемне балаларга бирәм»

Республика һөнәри осталык конкурсында лауреат исеме;

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» республика һөнәри осталык конкурсы кысаларында «Сыйныф җитәкчесе» номинациясе»ндә «Кеше тәрбияләү» Республика һөнәри осталык конкурсында лауреат исеме;

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» Республика конкурсы кысаларында"Педагог-оештыручы» номинациясендә «Кеше тәрбияләү» Республика һөнәри осталык конкурсында лауреат исеме;

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» Республика конкурсы кысаларында үткәрелгән «Иң яхшы педагог –психолог» Республика һөнәри осталык конкурсында лауреат исеме.

2.5.«Иң яхшы педагог-оештыручы» номинацияләрендә грант алу өчен иң яхшы педагог-оештыручыларны конкурс нигезендә сайлап алу түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

белем бирү оешмасында балалар һәм яшүсмерләр иҗтимагый оешмалары, берләшмәләр, укучылар үзидарәсе органнары эшчәнлегендә катнашучы укучылар өлеше ( % );

соңгы өч елда укучыларның төрле дәрәҗәдәге социаль-педагогик юнәлештәге конкурс чараларында, фестивальләрдә катнашуын тәэмин итү;

соңгы өч елда төрле дәрәҗәдәге социаль юнәлешле конкурс чараларында укучыларның катнашу нәтиҗәлелеге;

педагогик хезмәткәрнең инновацион эшчәнлектә катнашуы, эксперименталь эш алып баруы, балалар иҗтимагый оешмалары һәм укучыларның үзидарә органнары эшчәнлегенә яңа технологияләр һәм эш формаларын кертүе;

соңгы өч елда педагогик хезмәткәрләрнең методик берләшмәләр эшендә, белем бирү процессын программалы-методик тәэмин итүдә, төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык бәйгеләрендә катнашуы;

проект эшчәнлегендә катнашу, балалар иҗтимагый берләшмәсен үстерүгә грантлар җәлеп итү;

соңгы өч елда педагогик хезмәткәрнең үз һөнәри эшчәнлегенең практик нәтиҗәләрен тарату буенча чараларда катнашуы (мастер-класслар, тренинглар, стендлы яклау, семинарларда, вебинарларда, конференцияләрдә, педагогик укуларда докладлары).

2.5. «Психологик-педагогик хезмәтнең иң яхшы педагог-психологы (ППМС-Үзәк)» номинациясендә Татарстан Республикасы мәгариф системасының мәгариф оешмаларында белем бирү процессы субъектларына психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы муниципаль психологик-педагогик хезмәтләрнең һәм ППМС-үзәкләрнең педагог-психологларына ярдәм күрсәтү буенча конкурс түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

педагог-психологның Психологик десантта эшләү саны;

педагог-психологның инновацион эшчәнлектә катнашуы, экспериментal эш алып бару (расланган сертификатлар булу);

соңгы өч елда педагог-психолог ның төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык конкурсларында катнашу нәтиҗәлелеге;

психологик-педагогик ярдәм күрсәтү нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән грантларда катнашу;

соңгы өч елда педагог-психологның үз психологик-педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү буенча чараларда (фәнни –практик конференцияләрдә, өйрәтүче семинарларда, мастер –классларда) катнашуы (чыгышлары һәм публикацияләре).

2.7. «Дәүләт бюджет оешмасы гомуми белем бирү оешмасының, иң яхшы педагог-психологы» номинациясендә ата - ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруда, гаиләләрне әзерләү һәм аларга ярдәм итүдә Татарстан Республикасы мәгариф системасының мәгариф һәм дәүләт бюджет оешмаларында белем бирү процессы субъектларына психологик-педагогик ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручыурта гомуми белем бирү мәктәпләре, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, балалар йортлары педагог-психологларын грант алуга конкурс сайлап алу түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

педагог-психологның инновацион эшчәнлектә катнашуы,

эксперименталь эш алып бару (раслаучы сертификатлар булу); соңгы

соңгы өч елда педагог-психологның төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык конкурсларында катнашу нәтиҗәлелеге;

психологик-педагогик ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән грантларда катнашу;

соңгы өч елда педагог-психологның үзенең психологик-педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү буенча чараларда (фәнни-гамәли конференцияләрдә, укыту семинарларында, мастер-классларда) катнашуы; әлеге белгеч эше турында клиентларның уңай фикерләре.

2.8.«Һөнәри белем бирү оешмасының тәрбия эше буенча иң яхшы директор урынбасары» номинациясендә грант алуга һөнәри белем бирү оешмаларының иң яхшы директорларын конкурс нигезендә сайлап алу һөнәри белем бирү оешмаларының 2017-2018 уку елы рейтинг нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге критерийлар буенча үткәрелә:

гражданлык-патриотик тәрбия чараларында һөнәри белем бирү

оешмасының катнашу нәтиҗәлелеге күрсәткече;

һөнәри белем бирү оешмасының студентлар үзидарәсе органының эш нәтиҗәлелеге күрсәткече;

һөнәри белем бирү оешмасының сәламәтлекне саклау һәм спорт-сәламәтләндерү хезмәте эшенең нәтиҗәлелеге күрсәткече;

2017-2018 уку елында һөнәри белем бирү оешмасының мәдәни-массакүләм чараларда катнашу нәтиҗәлелеге күрсәткече;

һөнәри белем бирү оешмасы укучыларының хокук бозуларны профилактикалау хезмәте эшенең нәтиҗәлелеге күрсәткече;

һөнәри белем бирү оешмасында тәрбия эшенең төп юнәлешләре нигезендә планлаштырылган һәм методик документлар булу.

## 3. Грант алуга конкурс сайлап алуны үткәрү тәртибе

3.1 .Грант бирүче гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганчы, 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Республика мәктәптән

тыш эшләр үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе сайтында (алга таба - ДБУ «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге») мәгълүмат урнаштыру юлы белән конкурс үткәрү турында игълан итә.

3.2. Грант алуга дәгъва кылучыларны тәкъдим итү аларның ризалыгы белән үткәрелә:

гариза бирүчеләр белән;

үз-үзен күрсәтү юлы белән .

3.2.1. 2018 елның 4 июненә һәм 10 июненә кадәр гариза бирүченең әлеге нигезләмәнең №1 кушымтасы нигезендә грантка дәгъва кылучыны тәкъдим итү турында гаризасы яки әлеге Нигезләмәнең 6 нчы кушымтасы нигезендә (үз үзен күрсәткәндә) грантка дәгъва кылучының т гаризасы 2018 елның 4 июненә кадәр түбәндәге адрес буенча бирелә:

420036, Казан ш., Тимирязев ур., 8а, а/я 36, ДБО "Республика мәктәптән тыш эшләр үзәгенең «Грант» номинацияләр __________» тамгасы белән, «Балаларга өстәмә белем бирү оешмасының иң яхшы директоры», «Балаларга өстәмә белем бирүнең иң яхшы методисты», «Балаларга өстәмә белем бирүнең иң яхшы педагогы», «Иң яхшы педагог-оештыручы», «Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре» номинациясе;

2018 елның 10 июненә кадәр 420036, Казан ш., Тимирязев ур., 8а, а/я 36, ДБО «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге Грант, номинация_____» тамгасы белән, «Һөнәри белем бирү оешмасының тәрбия эше буенча иң яхшы директор урынбасары» номинациясе;

2018 елның 4 июненә кадәр

420057, Казан шәһәре., ур Ак. Королев, 4Б. «Грант,номинация___________» тамгасы белән «Росток» республика психологик-педагогик ярдәм үзәге дәүләт автоном белем бирү учреждениесе, «Иң яхшы психолог-педагогик хезмәте (ППМС-Үзәк) педагог-психологы» номинациясе, «Белем бирү оешмасының, дәүләт бюджет оешмасының иң яхшы педагог-психологы», номинациясе.

2018 елның 4 июненнән һәм 10 июненнән соң тапшырылган Грант алуга конкурс материаллары каралмый.

Грант алуга конкурс материаллары рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

3.3. Мөрәҗәгать итүченең грантка дәгъва кылучыны тәкъдим итүе турындагы гаризасына (үз үзен үзе күрсәткән вакытта грантка дәгъва кылучының гаризасы) түбәндәге документлар теркәлә:

Грант алырга теләүченең эш бирүче тарафыннан таныкланганланган һөнәри белем турындагы диплом күчермәсе;

Грант алырга теләүченең хезмәт кенәгәсе күчермәсе яки әлеге вазыйфада кимендә өч ел стажны раслаучы эш урыныннан эш бирүче раслаган белешмә;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә грантка дәгъва кылучының ризалыгы (2 нче кушымта);

муниципаль һәм (яки) республика дәрәҗәсендәге Һөнәри берләшмәләрнең үтенечнамәсе;

эш бирүче яки гамәлгә куючы тарафыннан расланган, әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар нигезендә оештырылган, расланган документларны теркәп, грант алырга теләүченең һөнәри казанышлары турында мәгълүмат;

грантка дәгъва кылучы тарафыннан экспертиза өчен Республика комиссиясенә тәкъдим ителгән документлар исемлеге (3 нче кушымта).

3.4. Конкурс материалларын кабул итү, теркәү Республика комиссиясе тарафыннан башкарыла.

Документларны кабул иткәндә грантка дәгъва кылучыга теркәү номеры бирелә. Һәр грантка дәгъва кылучыга Республика комиссиясенә тапшырылган документларның техник экспертиза нәтиҗәсе (4 нче кушымта) рәсмиләштерелә.

3.5. Грант алуга Конкурс һәр номинация буенча читтән торып бирелгән документлар нигезендә әлеге Нигезләмәнең 2 бүлеге тарафыннан билгеләнгән конкурс сайлап алу критерийлары нигезендә баллар бирү юлы белән үткәрелә.

3.6. Һәр критерий буенча баллар саны Республика комиссиясе тарафыннан 5 баллы шкала буенча (0-5) Грантның конкурс материалларын бәяләү методикасы нигезендә билгеләнә (5 нче кушымта).

3.7. Грант алырга тәкъдим ителгән документларга экспертиза ясаучы эксперт төркемнәре составы Республика комиссиясе тарафыннан төзелә һәм Министрлык боерыгы белән раслана. Боерык расланган көндә министрлык һәм ДБУ «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге» рәсми сайтларында бастырыла.

3.8. Грантка дәгъва кылучылар документларының экспертиза нәтиҗәләре буенча эксперт бәяләмәсе төзелә, ул экспертиза үткәргән экспертлар тарафыннан имзалана.

3.9. Грант алуга конкурс нәтиҗәләре нигезендә Республика комиссиясе грантның һәр номинациясе буенча дәгъва кылучыларның рейтинг исемлеген төзи. Республика комиссиясенең эш нәтиҗәләре дәгъва кылучыларның рейтинг исемлекләре кушымталы беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3.10. Бер үк төрле балл җыйган һәм рейтингның түбән чигендә булган дәгъва кылучылар булганда, республика комиссиясе документлар буенча өстәмә экспертиза оештыра.

3.11. Өстәмә экспертиза нәтиҗәләре эксперт бәяләмәсендә һәм Республика комиссиясе беркетмәсендә чагылдырыла. Республика комиссиясе беркетмәсе нигезендә дәгъва кылучылар рейтингларына кирәкле үзгәрешләр кертелә.

3.14.Республика комиссиясе 1.10.2 пунктында һәр номинация өчен билгеләнгән квота нигезендә  Грант алучылар исемлеген төзи һәм аны Министрлыкка раслауга тәкъдим итә.

3.15 Тәкъдим ителгән исемлектән чыгып, Министрлык Грант алучыларның исемлеген раслап, грант нәтиҗәләре турында боерык чыгара. Грант нәтиҗәләре турында боерык расланган көндә Министрлыкның, ДБО «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге» һәм “Росток”Республика психологик-педагогик ярдәм үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең рәсми сайтларында бастырыла.

3.16. Грант алуга конкурс нәтиҗәләре турында боерык чыккан көннән алып 3 эш көне эчендә, электрон яки почта адресларына шәхси язма  аша хәбәр итү юлы белән һәр Грант алучыга җиткерелә.

3.17. Конкурс нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, дәгъва кылучы Грант бирү буенча Республика комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция

белән гариза, г рант нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, 10 эш көне эчендә, Республика комиссиясе рәисе исеменә ирекле рәвештә бирелә.

3.18. Республика комиссиясе апелляцияне 7 эш көне эчендә карый. Апелляция буенча Республика комиссиясе карарлары комиссия составының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавыш тигез булган очракта, Республика комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш бирергә хокуклы.

Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча Рреспублика комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара:

апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклап калу турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм грант алуга конкурс нәтиҗәләрен үзгәртү турында.

3.19. Конкурс материалларын бәяләү критерийлары апелляция предметы була алмый һәм яңадан карап тикшерелергә тиеш түгел. 3.20. Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча Республика комиссиясе карарлары ахыргы булып тора һәм яңадан карап тикшерелергә тиеш түгел.

3.21. Апелляцияне карау Республика комиссиясе тарафыннан рәис һәм барлык комиссия  әгъзалары кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

## 4. Грантны гамәлгә ашыру буенча Республика комиссиясе һәм Эксперт төркемнәре

4.1. «Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» грантын гамәлгә ашыру буенча Республика комиссиясе һәм эксперт төркемнәре Министрлык боерыгы белән раслана.

4.2. Республика комиссиясе грант алучыларның рейтинг исемлеген төзи һәм раслый.

4.3. Грантны гамәлгә ашыру буенча эксперт төркемнәре (алга таба - эксперт төркемнәре):

бәйсез эксперт төркемнәре карамагына кертелгән мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

кирәк булганда, конкурс материалларына өстәмә экспертиза үткәрү өчен белгечләрне җәлеп итәргә;

грант алырга теләүчеләрнең педагогик хезмәткәрләрен анкеталау үткәрергә хокуклы.

4.4. Республика комиссиясе һәм эксперт төркемнәре утырышлары кирәк булган саен уздырыла һәм, әгәр аларда аларның составының яртысыннан артыгы катнашса, хокукый булып санала.

4.5. Республика комиссиясе һәм эксперт төркемнәре карарлары, әгәр алар өчен исемлек составының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигезләшкән очракта Республика комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

4.6. Грант алучылар исемлеген килештерү турындагы карар тиешле эксперт подкомиссиясенең утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.7. Республика комиссиясе составында 8 әгъза.

4.8. Эксперт төркемнәре составында 3 әгъза һәм алар агымдагы елда үзләре грантка дәгъва кылучы булырга тиеш түгел.

## 5. Грантны Финанслау

5.1. Грант бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» гранты турында нигезләмәгә1 нче кушымта

Теркәлү номеры: _______
№ гаризаны теркәү датасы: ______

# ГАРИЗА БИРҮЧЕНЕҢ ГРАНТКА ДӘГЪВА КЫЛУЧЫНЫ ТӘКЪДИМ ИТҮЕ ТУРЫНДА

Грантка дәгъва кылучы турында
мәгълүматлар
Номинация (өстәмә белем бирү педагоглары өчен юнәлешне күрсәтергә)

Исем фамиясы атасының исеме_______________________________________________
Туган көне_____________________________________________________________
Паспорт мәгълүматлары (номер, серия, кем һәм кайчан бирелгән)________________
Прописка урыны буенча адрес_______________________________________________
ИНН__________________________________________________________________
Пенсия-иминият таныклыгы_________________________________________________
Ак барс банк картасы номеры________________________________________________
Элемтә өчен (Кәрәзле) телефон номеры____________________________________
Эш урыны *(Устав нигезендә белем бирү оешмасының тулы исеме):*________________________________ ________________________________

*Вазыйфасы (әлеге мәгариф оешмасында):*

*мәгариф оешмасының почта адресы:*

Элемтә өчен телефон:________________Факс:_________________________________
Email:____________________________________htpp:______________________Гомуми стажы педагогик эш / стажы әлеге вазыйфасында әлеге мәгариф оешмасында:___________________________________________________________
Мактаулы исемнәр:_________________________________________________________

Гариза бирүче турында мәгълүмат
*Мөрәҗәгать итүченең исеме (оештыру-хокукый формасы да кертеп)*:
Җитәкченең исем фамиясы атасының исеме, вазифасы________________________
Мөрәҗәгать итүченең факттагы адресы: ________________________________________
Элемтә өчен телефон:__________________________Факс:______________________
Мөрәҗәгать итүченең имзасы:____________________________________ __________

**Беркетмә № һәм грантка дәгъва кылучыларга тәкъдим итү буенча мөрәҗәгать итүче орган утырышы датасы**

*Әгәр мөрәҗәгать итүченең мөһере булмаса, мөрәҗәгать итүченең имзасы әлеге иҗтимагый орган яисә муниципаль бүлек (идарә) җитәкчесе тарафыннан раслана*

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» гранты турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

**ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК**

Мин,_______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

_________________________________________________________________________________

_____________________________серия_____________________________________

